Р Е С П У Б Л И К А Т А Т А Р С Т А Н
**Г Л А В А**
**СТАРОКАЗЕЕВСКОГО**
**сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**м у н и ц и п а л ь н о г о р а й о н а**

ул. Центральная, 7, д.Караталга, 422834
тел. (8-843-77)30-4-16, факс: (8-843-77)30-4-16
ОКПО 04306776 ОГРН 1031638402201
ИНН/КПП 1622001844/162201001

Т А Т А Р С Т А Н Р Е С П У Б Л И К А С Ы
***Кама Тамагы***
**м у н и ц и п а л ь р а й о н ы**
**ИСКЕ КАЗИЛЕ**
**авыл җирлеге**
**Б А Ш Л Ы Г Ы**

Үзәк урамы, 7 , Каратал авылы, 422834,
тел. (8-843-77)30-4-16 , факс: (8-843-77)30-4-16
ОКПО 04306776 ОГРН 1031638402201
ИНН/КПП 1622001844/162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**9 декабрь 2021 ел** **№ 28**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлегенең Иске Казиле авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама-Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Уставы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлегенең Иске Казиле торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын 2021 елнын 20 нче декабренэ билгеләргә:
    1.1. Халык жыенын уткэру вакыты - 2021 елнын 20 декабрендэ 10.00 сэгатьтэн 12.00 сэгатькэ кадэр.
    1.2. Уткэру урыны-Иске Казиле авылы, Шарлама урамы, МФЦ бинасы янында.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндэге мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлегенә кергән Иске Казиле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән (көндезге формада белем алучы студентлардан тыш) 2022 елда 1100 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны, җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча түбәндә язылган эшләрне хәл итүгә куллану белән килешәсезме:

1) Иске Казиле т. п. буенча юл-урам челтәрен төзекләндерү (вак таш сатып алу, ташу,  җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү) ;
2) Иске Казиле т. п. юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
3) Иске Казиле т.п. территориясен чуп улэннэреннэн чистарту (чапкыч очен запас частлэр сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).
4) Иске Казиле т. п. да янгын гидрантларын тэртиптэ тоту (янгын гидрантларын, краннарны (җайланмаларны) кышка җылыту, люкларны кардан, боздан даими чистарту, язгы-җәйге янгын куркынычы чорына әзерлек һәм тикшерү, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)
5) Иске Казиле т. п. зираты территориясен төзекләндерү (зиратны төзекләндерү – истәлек язуы урнаштыру, контейнер сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)
6) Торак пункт территорияләрен төзекләндерү (Иске Казиле авылы эчендәге карьерны бетерү (рекультивацияләү),урамда бизэу очен чыршы бизэклэре сатып алу) ;
7) Җәяүлеләр күперен ремонтлау (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

« ӘЙЕ»                «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына һәм җирлекнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Иске Казиле авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе ________________И.Х.Сәгдиев